РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ АРТАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422069, Республика Татарстан, Сабинский район,
д.Два поля Арташ, ул. Тукая, 61
тел. (84362) 44-7-15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АРТАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422069, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Ике басу Арташ авылы, Тукай урамы, 61 йорт
тел. (84362) 44-7-15

e-mail: Art.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
23.10.2024

КАРАР
№ 23

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Арташ авыл җирлеге Советының
29.09.2021 №19 карары белән расланган
Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Арташ авыл җирлеге чикләрендә
муниципаль җир контроле турында
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.08.2024 елгы №289-ФЗ Федераль закон нигезендә, Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне раслау хакында» 29.09.2021 елгы №19 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.11.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.11.3. Планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органнары белән килешү буенча гына үткәрелергә мөмкин «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә аны үткәрү очракларыннан тыш.»;

1.2. 5.12.4. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12.4. Әлеге Нигезләмәдә 4.2.1. пунктының 2 пунктчасында каралган урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул ителергә тиеш түгел.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/artash адресы буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.

Арташ авыл җирлеге Башлыгы Р.И.Мөхәрләмов